ПРОЕКТ

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

КАРАР

2016 елның ___ ноябре № ___

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Советы Татарстан Республикасы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

3. Әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырырга.

4. Карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2016 елның 5 декабренә 10.00 сәгатьтә район мәдәният йортында (тамаша залы) билгеләргә.

Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2006 елның 17 октябрендәге 11/6 номерлы карары белән расланган гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибенә ярашлы рәвештә үткәрелә, ул Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Чүпрәле муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырылган.

5. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу Чүпрәле муниципаль районы Советының 2012 елның 25 апрелендәге 18/1 номерлы карары белән расланган, ул Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган һәм «Туган як» газетасында бастырып чыгарылган.

6. Әлеге проект буенча гражданнарның искәрмәләре һәм тәкъдимнәре 2016 елның 4 декабренә кадәр Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урамы, 13 нче йорт, 114 нче кабинет адресы буенча кабул ителә.

7. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының законлылыкны үтәү һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиясе Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм гражданнарның карар проектына тәкъдимнәрен өйрәнергә

һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы каравына кертергә.

8. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда билгеләнгән башка срокларда үз көченә керә торган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан көнне үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы

Советының 2016 елның "__"__________ ____ номерлы карарына кушымта

.

.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

.

.

**71 статьяның 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

«14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.»;consultantplus://offline/ref=BED3314E57ACE272FCF7B748AE4D70339DC17F8ACFE83459B8E39A5308q1l4G

**44 статьяда:**

**2 пунктта түбәндәге** эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Татарстан Республикасының «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль - шәхси партнерлык турындагы килешүләрнең ягы булып тора;»;

**7 пунктны киләсе эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга**:

« - Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра.»;

**652 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«$65^2$ статья Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан чикләүләрне һәм тыюларны үтәү турында**

Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затның вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм

аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.;

**66 статьяга киләсе эчтәлектәге 7 пунктны өстәргә**:

«7. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, Татарстан Республикасы Законы нигезендә район башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә районның җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган экспертизага тиеш.»;

**69 статьяны киләсе эчтәлектәге 3-4 пунктлар белән тулыландырырга**:

«3. Районның эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган яңа яисә үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлары проектлары, Татарстан Республикасы Законы нигезендә, район башкарма комитетының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, район җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысын бәяләргә тиеш, моннан тыш:

1) муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары җирле салымнар һәм җыемнар билгели, үзгәртә, туктатып тора, юкка чыгара торган норматив хокукый актлары проектлары;

2) бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары норматив хокукый актлары проектлары.

4. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә.».

Татарстан Республикасы Чүпрәле Муниципаль районы Башлыгы урынбасары:
А.И.
. Сарафанов